**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**25 октябрь 2024 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, гаиләләре махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасыннан мобилизацияләнгән көндезге формадагы студентлардан тыш, II төркем инвалидлар өчен, Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Тымытык авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Тымытык авылында Нефтьчеләр, Чапаев, Ульянов урамнарында вак таш җәелгән юлны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авыл җирлегенең автомобиль юлларын тоту (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева